Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авыл җирлегендә гражданнар җыены

**КАРАРЫ**

14 ноябрь 2025 ел № 3

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Югары Ырга авыл җирлеге составына керүче Югары Ырга авылындагы гражданнар җыены нигезендә **карар кабул ителде**:

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең Югары Ырга авыл торак пунктында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән (уку йортларына йөреп укучы студентлардан,балачактан инвалид, беренче торкем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм алырның гаиләләреннән гайре ) 1000 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә;

2. Салым акчасын түбәндәге эшләрне башкару өчен тотарга:

– торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

– су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

– торак пункт территориясен төзекләндерү.».

-урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

3. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Югары Ырга авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Яна Ырга авылы, Мәктәп урамы, 48 йорт; Югары Ырга авылы, Муса Җәлил урамы, 18 йорты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирлеге башлыгы Кашапов А.А.